# Хайваннар - безнең дуслар!



# Йорт хайваннары



# Сыер

**Безнең сыер**

— Әби, әби, әйт әле,
Сыер нигә мөгери?
— Карыны ачкан, улым,
Печән китер, йөгер,— ди
— Ашап туйгач, ник сые
Сузып-сузып «Му-у» ди
— Эчәсе килгән, улым,
Китер миңа су-у! — ди ул.
(Н. Каштан)



# Ат

*Аттан башлыйк бер сүзне:*
*Ат була ике күзле,*
*Ике колак, дүрт аяк,*
*Һәр аяк саен тояк.*

*Тоякка каксаң дага,*
*Бахбай какмыйча чаба.*
*(Э. Мостафин)*



# Кәҗә белән сарык



**Кәҗә белән сарык хикәясе**
**… Кәҗә, Сарык, күргәч ушбу тамашаны,**
**Калды куркып, һәрберсенең ярты җаны.**
**«Исәнмесез, дустлар, Бүре әфәнделәр!» —**
**Диләр болар, күрсәтмичә курку хәле.**

**Куаналар өч-дүрт Бүре, моны күргәч,**
**Алларына Сарык белән Кәҗә килгәч:**
**«Ашыйбыз, дип, бу икәвен тотабыз да,**
**Менә ничек ит таптык, дип, буткабызга!»**



**Кәҗә әйтә: «Кайгырмагыз, бездә ит күп;**
**Ул ит берлән һәркайсыбыз булырбыз тук!**
**Ни карыйсың? Тиз бул әле, тиз бул, Сарык!**
**Капчыктагы Бүре башын китер алып!»…**
**( Г. Тукай)**

# Әтәч белән тавык


**Әтәч**

**Иртән бик иртә тора,**
**Канат кагып кычкыра:**
**— Кикрикүк! Кикрикүк!**
**Тор иртәрәк: эшең күп...**
**(Г. Лотфи)**



**Тавык**

**Кытаклап чыкты тавык,**
**Кытаклый ул мактанып.**
**Нәрсәгә бик шатланган?**
**Чөнки ул күкәй салган.**
**«Әби килеп алсын,— ди,**
**— Балалар куансын»,— ди**
**(Ә. Кари)**
**.**



# Эт

**Акбайга**

**Йөрмә, Акбай, безнең янда,**
**Я тешләрсең, кит әле.**
**Песиебезгә дә өрмә –**
**Ул бәләкәй бит әле.**

**Юлбарыска охшаган ул**
**Безнең песи баласы.**
**Чынлап юлбарыс булган, д**
**Аның ерак бабасы.**

**Ул да, үскәчтен, юлбарыс**
**Булыр әле – күрерсең.**
**Алай бик батыр икәнсең –**
**Менә шунда өрерсең!**
**(Р.Миңнуллин)**



# Песи

**Мияубикә**

**Мияубикә, Мияубикә,**
**Бигрәк инде чиста син.**
**Ашап туйгач битләреңне**
**Юарга бик оста син.**

**Тик һаман да сүзләремн**
**Колагыңа элмисең.**
**Ашаганчы да юыну**
**Кирәклеген белмисең**

**(Д.Гарифуллин)**



# Кыргый хайваннар



# Куян

Куян салкыннан
Туңган, куырылган,
Башы салынган,
Колагы шиңгән.
Әйдәгез, дуслар,
Аны терелтик,
Җылы бүлмәгә,
Мәктәпкә илтик.
Куян уянды,
Куркып уйланды,
Сикреп урманга
Чабып югалды.

— Куян, син кайда?
— Яшел тугайда.
— Куян, син кайда?
— Ерак чүлләрдә.
— Куян, син кайда?
— Калын урманда.
— Куян, син кайда?
— Карлы буранда.
Әйдәгез, дуслар,
Кырны, урманны,
Чүлне актарып
Табыйк куянны.
(М.Җәлил)



# Төлке

**Төлке белән Каз**

**Бервакыт Төлке Казны тотып алган да:**

**— Каз, мин сине ашыйм,— дигән.**

**Каз боегып калган.**

**— Мин риза, Төлке. Тик син миңа бер биеп калырга рөхсәт ит,— дигән Каз.**

**— Әйдә, бие,— дигән Төлке.— Ашарга өлгерермен әле. Каз, канатларын җилпеп, бер урында тыпырдый башлаган. Төлке:**

**— Әй оста биисең, Каз,— дип көлә икән.**

**Ә Каз, канатларын җилпеп, бер урында торган-торган да очкан да киткән.**

**Төлке авызын ачып калган.**

***(Татар халык әкияте)***



# Бүре

Яхшы ишетә, күрә,
Исне дә бик тиз сизә.
Улап, ауга чакыра_
Төнге урманны гизә.



Сорыдыр төсе,
Үткендер теше.
Урманда йөри,
Бозаулар эзли
(Табышмаклар)

# Тиен

**Урманда бар зур койрыклы**

**Җитез тиен.**

**Агач башларында яши**

**Кышын-җәен.**

**Агачлардан агачларга**

**Сикереп үтә,**

**Чиклэвеклэр ашап,шунда**

**Гомер итә.**

**(Ә. Кари)**



# Керпе

Ул өстенә җәй дә, кы
Энәле күлмәк кия.
Шулай да аны энисе
“Йомшагым” диеп сө

Әлем, әлем, әлем ку
Бөгәрләнгән мәче к
Аны кеше тоталмы
Тәпиләрен күралмы.
(Табышмаклар)



# Аю

**Салкын кышны сизли ул,**
**Ап-ак карны күрми ул.**
**Тирән йокыда аю,**
**Кайда аңа уяну.**

**Җиргә җылы яз килгәч,**
**Кояш нурларын сипкәч**
**Карлар суга әйләнгәч,**
**Гөрләвекләр йөгергәч,**

**Булган көчен югалтып,**
**Хәле китеп, ачыгып.**
**Йокысыннан уяна,**
**Аю язга куана.**
**(Л. Гиматдинова)**



# Поши

**Башында үсә куак -**
**Шуны табып**
**куандык.**
**Бу җәнлек безгә**
**ошый:**
**Исеме аның -?**

**Куаклар арасыннан**
**Куркып кына чыга да**
**Кинәт сикерә, чаба…**
**Һәм күздән дә югала.**
**( Табышмаклар)**

